Татарстан Республикасы Хисап палатасы

2015 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында
ХИСАП

Казан – 2016 ел

Эчтәлек

Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре.....3

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге 5

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге.....111

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары, Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек.....42

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек **Ошибка! Закладка не определена.**

Эшчәнлектәге хәбәрдарлык 47

2015 елда Татарстан Республикасы эше турында хисап

Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба – Хисап палатасы) эше турында хисап Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының Хисап палатасы турында» Законының 33 маддәсенә яраштырып зәерләнде.

Хисапта Хисап палатасының 2015 елда законнар тарафыннан билгеләнгән бурыч һәм вәкаләтләрне үтәү буенча эшчәнлеге нәтиҗәләре тәкъдим ителгән.

Эшчәнлекнең төп күрсәткечләре

2015 елда Хисап палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетын, Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетын формалаштыру һәм үтәүне тикшерү буенча, дәүләт милке белән идарә итү һәм файдалану өлкәсендә 160 тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика чарасы үткәрелде.

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча гомуми күләме **2 323 779,1 мең сум** булган бозулар **ачыкланган,** гомуми күләме **2 056 006,2 мең сумлык** чара барлык дәрәҗәдәге бюджетларга **кире кайтарылган** һәм ачыкланган бозулар буенча **чара күрелгән** (ачыкланган бозуларның 88,5%ы).

Ачыкланган бозулар турында мәгълүмат һәм барлык тикшерү чаралары буенча материаллар Татарстан Республикасы Прокуратурасына җибәрелде.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм прокуратура органнары күрсәтмәләре буенча **дисциплинар җаваплылыкка 151 вазыйфаи зат тартылды, 4 вазыйфаи зат** эштән азат ителде. **Административ җаваплылыкка 3 юридик зат һәм 63 вазыйфаи зат тартылды.**

2015 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында хисап

Хисап палатасы эшчәнлегенең төп күрсәткечләре таблицада бирелгән.

Күрсәткеч атамасы	2011 ел	2012 ел	2013 ел	2014 ел	2015 ел
I. Тикшерү-ревизия эшчәнлеге					
Үткәрелгән тикшерү-ревизия чаралары саны	50	53	53	54	53
Тикшерү-ревизия чаралары үткәргәндә җәлеп ителгән объектлар саны (берәмлек)	481	483	487	491	489
Ачыкланган бозулар күләме (мең сумнарда)	3 035 829,8	3 043 991,9	2 615 511,7	2 349 977,6	2 323 779,1
II. Экспертиза-аналитика эшчәнлеге					
Үткәрелгән экспертиза-аналитика чараларының гомуми саны	112	108	115	108	107
Әзерләнгән экспертиза бәяләмәсе	47	43	68	57	70
Әзерләнгән методик документлар	2	4	8	3	3
III. Тикшерү чаралары нәтиҗәләрен тормышка ашыру					
Чаралар күрү өчен җибәрелгән күрсәтмәләр	59	56	42	36	60
Бюджетка торгызылган чаралар һәм күрелгән чаралар (мең сумнарда)	1 922 464,6	2 530 004,3	2 303 355,3	2 150 982,7	2 056 006,2
Тикшерү материаллары нәтиҗәләре буенча прокуратура органнарына һәм хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны (берәмлек)	55	58	61	54	53
Хисап палатасы тикшерү материаллары буенча административ җаваплылыкка тарту турында суд һәм башка вәкаләтле органнар кабул иткән карарлар саны	35	33	34	40	66
Хисап палатасы материаллары буенча кузгатылган җинаять эшләре саны	3	4	9	2	2

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге

2015 елда Татарстан Республикасы бюджетын һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетын (алга таба текст буенча – Татарстан Республикасы ММИ территориаль фонды) формалаштыру һәм үтәүне тикшерү кысаларында 107 экспертиза-аналитика чарасы үткәрелде.

Законнар проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында бәяләмәләр – Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, дәүләт программалары проектларына бәяләмәләр билгеләнгән вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдим ителде.

Хисап елында Татарстан Республикасы Хисап палатасының эшчәнлеген методология ягыннан тәэмин итү максатында тышкы дәүләт финансы тикшерүенең 3 стандарты эшләнде.

Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы комиссиясе эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы Хисап палатасы тышкы дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүенең 5 стандартын эшләүдә катнашты.

«2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» законы проектына экспертиза барышында закон проектының бюджет законнарына туры килүе мәсьәләләре каралды, шулай ук закон проекты белән бер үк вакытта тәкъдим ителгән исәпләүләр һәм документларга анализ үткәрелде.

Экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәдә 2016 елга һәм 2017 һәм 2018 еллар планлы вакытына республика бюджеты проектын төзегәндә нигез итеп алынган төп макроикътисадый күрсәткечләр фаразы Россия Федерациясе дәрәҗәсендә кабул ителгән икътисадны үстерү вариантларын формалаштыру өчен башлангыч шартларны исәпкә алып формалаштырганлыгы билгеләнде.

Бәяләмәдә шулай ук Татарстан Республикасының 2016 елгы бюджетының керем һәм чыгымнар күрсәткечләре соңгы булмавы һәм, федераль дәрәҗәдә Россия Федерациясе субъектлары буенча чараларны бүлүне исәпкә алып, төзәтмәләр кертеләчәге күрсәтелде.

2016 елга бюджет проектының үзенчәлеге булып Татарстан Республикасы дәүләт программалары буенча чыгымнарны формалаштыру тора.

Бәяләмәдә бюджетны раслаганнан соң 22 дәүләт программасы буенча, 2016 елга билгеләнгән бюджет ассигнованиеләре күләмен истә тотып, параметрларны тәгаенлау кирәклеге билгеләп үтелә.

Татарстан Республикасының «2016 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында» законы проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча тәкъдим ителгән закон проектының бюджет проектын формалаштыруга һәм аның эчтәлегенә бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе билгелә үтелә.

2016 елга Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджет проекты балансланган – керемнәр һәм аның дефицитын финанслау чыганакларыннан кертемнәр күләме алдан каралган чыгымнар күләменә туры килә.

Хисап вакыт аралыгында **Татарстан Республикасының «2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Законына үзгәрешләр кертү турында** законнарының 4 проектына экспертиза һәм **Татарстан Республикасының «2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында» Законына үзгәрешләр кертү турында** законнарның 2 проектына экспертиза үткәрелде.

Татарстан Республикасының **«Яшь ярымнан өч яшькәчә балалар тәрбияләүче аерым категория гражданнарга ай саен бирелә торган акчалата түләүләр бирү турында»** законы проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча түләүләрнең гомуми күләмен ачыклаганда чыгымнарның аерым төрләрен исәпкә алу өлешендә искәрмәләр була. Закон проектына бәяләмәдә шулай ук акчалата түләүләрнең күләмен индексациялә̆ү мәсьәләсен өстәмә эшләү кирәклеге турында да әйтелә.

Татарстан Республикасының **«Татарстан Республикасында җәмәгать тәртип саклау пунктлары турында»** законы проектына бәяләмәдә закон проекты белән бер үк вакытта бирелгән материалларда законны тормышка

ашыруга республика бюджеты чараларының планлаштырылган күләменең җитәрлек булуын раслаучы исәп-хисаплар булмавы билгеләп үтелә.

Татарстан Республикасының **«Татарстан Республикасының Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында», «Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләргә финанс ярдәме күрсәтү региональ фондларыннан шәһәр, авыл җирлекләренә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында», «Татарстан Республикасының «Оешмаларның милкенә салым турында» законының 3 һәм 5 нче маддәләренә үзгәрешләр кертү турында», «Татарстан Республикасының «Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана торган салым түләүчеләр өчен дифференцияләнгән салым ставкалары билгеләү турында» законының 2 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында», «Татарстан Республикасына федераль бюджеттан бюджет кредитлары бирү турында өстәмә килешүләрне раслау», «Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» законына үзгәрешләр кертү турында»** законнары проектлары эчтәлегенә искәрмәләр һәм тәкъдимнәр булмады.

Хисап елында бюджет законнарына бәйле рәвештә **2014 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында Хисапка тышкы тикшерү** үткәрелде, ул республика бюджеты чараларының төп администраторларының бюджет хисаплылыгын тикшерүне үз эченә алды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча бюджет хисаплылыгының гомумән алганда норматив хокук актларына туры килгәнлеге билгеләнде. Ачыкланган кимчелекләр бюджет хисапларын төзү һәм бирүгә таләпләрне саклауга кагыла һәм бюджет үтәлеше күрсәткечләренә йогынты ясамый. Татарстан Республикасы Хисап палатасына закон тарафыннан билгеләнгән вакытка еллык хисапларын тапшыруда бозулар җибәргән министрлык һәм ведомстволарга күрсәтмәләр җибәрелде.

Хисап палатасы бәяләмәсендә бюджет үтәлешенә керемнәр, чыгымнар һәм дефицитны финанслау чыганаклары буенча бәя бирелгән, 2014 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисап күрсәткечләренең тулылыгы һәм дөреслеге расланды.

2014 ел өчен Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында Хисапны тышкы яктан тикшерү нәтиҗәләре буенча еллык хисапта дөрес һәм тулы булмаган фактлар булуы ачыкланмады.

Татарстан Республикасының **«2014 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында»** һәм **«2014 ел өчен Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында»** законнары проектларына экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрдә законнар проектлары һәм кушымталар күрсәткечләренең тышкы тикшерү үткән 2014 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында хисаплар күрсәткечләренә туры килүе билгеләнде. Законнар проектларының һәм аларның кушымталарының составы, эчтәлеге законнар белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирә.

2015 елда түбәндәге 3 дәүләт программасы буенча һәм гамәлдәге дәүләт программасына үзгәрешләрнең 1 проектына экспертиза үткәрелде һәм бәяләмә әзерләнде:

- «2015-2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегияле идарә итү» дәүләт программасы проекты;
- «2016-2018 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларга үз теләкләре белән Татарстан Республикасына күчәргә ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы проекты;
- «2016-2020 елларга Татарстан Республикасында товар аквакультурасын (товар өчен балыкчылыкны) үстерү» дәүләт программасы проекты;
- «2014-2020 Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик тәрбия һәм спортны үстерү» дәүләт программасына кертелә торган үзгәрешләр проекты.

«2015-2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегияле идарә итү» дәүләт программасы проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча программаны тормышка ашыру барышын тикшерү өчен өстәмә шартлар тудыру һәм республика бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып үз вакытында төзәтмәләр кертү максатларында, финанс ресурслары күләме белән бәйләп, чараларны детальләштерергә тәкъдим ителде. Бер үк затка программа чараларын тормышка ашыру һәм аларның үтәлешен тикшерү буенча вәкаләтләрне бирүгә бәйле рәвештә, дәүләт программасын

үтәү барышы һәм нәтиҗәләрен бәяләүнең объективлыгы түбәнәю куркынычы күзәтелгән.

«2016-2020 елларга Татарстан Республикасында товар аквакультурасын (товар өчен балыкчылыкны) үстерү» дәүләт программасы проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәдә дәүләт программасы проектына финанс-икътисадый нигезләүдә планлаштырылган күләмнәрдә финанслауга ихтыяҗны раслаучы мәгълүмат юклыгы, республика бюджетыннан финанслау карала торган аерым чаралар буенча индикаторлары куелмавы билгеләнә.

«2016-2018 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызга үз теләкләре буенча Татарстан Республикасына күчеп кайтуга ярдәм итү» дәүләт программасы проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча программа чараларын (уку, яшәү, медицина ярдәме күрсәтүнең бәясе) тормышка ашыру кысаларында куела торган бер проектта катнашучыга хезмәт күрсәтүне ачыклауга кабул ителгән якын килүләр турында мәгълүмат булмавы билгеләп үтелә, бу финанслауның бюджет чыгымнарының экономиялелеге һәм нәтиҗәлелеген тәэмин итү предметына планлаштырыла торган күләмнәренең нигезлелегенә бәя бирү мөмкинлеген юкка чыгара.

Хисап елында бюджетның агымдагы үтәлешен тикшерү кысаларында квартал саен бюджетлар дефицитын каплау өчен җәлеп ителә торган чараларның күләмнәре һәм төзелеше, чыганаклары һәм күләмнәре буенча Татарстан Республикасы бюджеты һәм ММИ Территориаль фонды бюджетының керемнәр кертемнәре күрсәткечләренә һәм тотылган чыгымнарга анализ ясалып торды.

Шулай ук Татарстан Республикасы ачык норматив йөкләмәләрен, дәүләт программаларын, программа характерындагы чараларны үтәүгә үз вакытында финанслау һәм чыгымнар үтәлеше, республиканың муниципаль берәмлекләре бюджетларына трансфертлар бирү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Резерв фонды чараларын тоту мәсьәләләре дә каралды. Дәүләт бурычы һәм аңа хезмәт күрсәтүгә чыгымнар торышы, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән кредитлар буенча бурычлар торышы, республиканың бюджет алучыларының дебиторлык һәм кредит бурычлары күләменә мониторинг уздырылды.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджетының агымдагы үтәлешен тикшерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бюджетлар үтәлеше турында хисаплары, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе белешмәләре, республика бюджет чаралары төп җитәкчеләренең хисаплары нигезендә Федераль казначылыкның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлешенең нәтиҗәлелегенең мөһим күрсәткечләренең мәгълүмати- аналитика системасы мәгълүматларын кулланып үткәрелде.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджетының үтәлеше буенча анализ нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Хисап палатасының квартал саен бәяләмәләрендә чагылдырылды.

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге

2015 елда Хисап палатасы **53** тикшерү-ревизия чарасы үткәргән, **489** объект тикшерелгән.

Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенең аерым мәсьәләләре буенча тикшерү чаралары 14 министрлыкта һәм ведомствода, Татарстан Республикасының 18 муниципаль районында үткәрелгән.

Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе буенча объектларны реконструкцияләү һәм төзү, капиталь ремонт вакытында куллана торган материалларның бәясе, хакларының нигезле булуына аудит үткәрелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәләре буенча:

- Татарстан Республикасының торак пунктларын су белән тәэмин итү системаларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтка 2012-2014 елларда һәм 2015 елның үткән вакытында бүлеп бирелгән дәүләт чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит;

- ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча чараларны тормышка ашыруга 2012-2014 елларда һәм 2015 елның үткән вакытында Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрелде.

Хисап палатасы Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәте мәсьәләләре буенча идарәсе белән берлектә Әлмәт, Балтач, Түбән Кама, Питрәч муниципаль районнарында, Яр Чаллы шәһәрендә (спорт-сәламәтләндерү комплекс төзелеше объектлары) һәм Казан шәһәрендә («Водоканал» МУП) коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыруда гамәли ярдәм күрсәтү буенча комплекслы чаралар үткәрүдә катнашты.

Татарстан Республикасы Прокуратурасы мөрәҗәгате буенча «Теләче» Сәнәгать (индустриаль) паркы, «Мамадыш ҮРХ» ДАССУ һәм «Нурлатская ҮРХ» ДАССУ эшчәнлеген, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануның максатчанлыгын һәм нәтиҗәлелеген тикшерү уздырылды.

Комплекслы һәм тематик тикшерүләр үткәргәндә түбәндәге бозулар ачыкланды:

- бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгын алып баруда – 1 073 014,7 мең сумга;

- дәүләт (муниципаль) милкен кулланганда һәм идарә иткәндә – 930 846,8 мең сумга;

- бюджет чараларын нәтиҗәсез файдалану – 121 462,6 мең сум;

- дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен товарлар, эш һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә бозулар – 27 772,1 мең сум;

- бюджет чараларын максатсыз файдалану – 2 119,1 мең сум;

- башка төр бозулар (хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләргә булган ихтыяҗдан артык чаралар күчерү, Россия Федерациясе Бюджет классификациясен куллану тәртибе турында күрсәтмәләрне бозулар, керемнәр администраторы функцияләрен башкарганда бозулар, башкарылган эшләр өчен түләү бәясен бозу, башкарылмаган, әмма подрядчыдан заказ бирүче кабул иткән эшләр өчен түләү һәм башкалар) – 168 563,8 мең сум.

2015 елда уздырылган тикшерү чаралары барышында
Татарстан Республикасы Хисап палатасы ачыклаган
финанс бозулары төзелеше

2011-2014 елларга фән, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә грантлар түләүгә Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә үткәрелгән **аудит** гомумән алганда грант ярдәме формасындагы республика бюджеты чаралары шул максатта файдаланылганлыгы һәм республика халкының мәдәни – белем дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итүен күрсәтте. Шуның белән беррәттән, кайбер очракларда грант проектларының тормышка ашыруның чынбарлыктагы бәяләре грант

алырга теләүче тәкъдим иткән бәядән дә, грант бирә торган министрлык раслаган бәядән дә түбәнрәк булып чыга, сметада каралмаган чыгымнар чыгарыла, бу смета билгеләнешләренең ачык нигезләнмәгән булуын, грант алучы алдына куелган максат һәм бурычларга ирешүгә тотылган чыгымнар белән бәйләү булмавын күрсәтә.

Мәдәният һәм мәгариф учреждениеләрендә 17 күчмә тикшерү чарасы 1 300 мең сумга алынган милекнең нәтиҗәсез куллану фактларын ачыклаган.

Буа Мәктәптән тыш эш үзәгендә «Дәресләрдән соң мәктәп» грантын тормышка ашыруга бүлеп бирелгән кирәкле бина һәм белгечләр булмау сәбәпле 172 мең сумлык җиһаз файдаланылмаган. .

Контрактта күрсәтелгән белән чагыштырганда күпкә арзанрак аналоглар белән тәэмин итү фактлары ачыкланган.

Тәтеш районының кино-видео хезмәте күрсәтү буенча муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенә бәясе 29 мең сум булган «Sony» планшетлы персональ компьютер урынына тикшерү көненә базар бәясе 8 мең сум булган «Asus» планшеты китерелә. Тикшерү барышында китерелгән җиһазны тулысынча алмаштыру узды.

Баулы шәһәренең 2 нче номерлы мәктәбенә «Дәресләрдән соң мәктәп» проекты кысаларында 2014 елның сентябрендә түләнгән робототехника буенча өч комплект китерелмәгән. Тикшерү нәтиҗәләре буенча җитешми торган җиһазлар мәктәпкә тулысынча кайтарылды.

Аудит нәтиҗәләре буенча Экспертлык советы тарафыннан хупланган тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр әзерләнде.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан Мәдәният һәм сәнгать муниципаль учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турында нигзләмәгә үзгәрешләр әзерләнде.

Җибәрелгән бозулар һәм кимчелекләр өчен мәгариф учреждениеләренең 8 вазыйфаи заты дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Бюджет чаралары хисабына объектлар төзү һәм реконструкцияләү, капиталь ремонтау вакытында кулланыла торган **материаллар бәясе, хакларының нигезлелегенә аудит** уздырылды. Татарстан Республикасында төзелештә бәяләр ясалу һәм сметаны нормага салу буенча функцияләрне «Республика инженерлык-техник үзәге» ҖЧҖ базасында эшләүче Бәя барлыкка китерүнең региональ үзәге башкарды.

Уздырылган аудит нәтиҗәләре Татарстан Республикасында социаль әһәмияткә ия объектлар төзелеше бәясенең уртача Идел буе федераль округының башка регионнарына караганда түбәнрәк булуын күрсәтте. Мәсәлән, балаларга мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре төзелешендә бер квадрат метрның уртача бәясе 28 мең сум тәшкил итә, бу – Идел буе федераль округы буенча уртача 14%ка кимрәк.

2004-2014 еллар өчен капиталь төзелеш объектлары смета бәясен формалаштырганда исәпкә алына торган хезмәткә түләү фонды һәм төзелеш тармагы хезмәткәрләренең исәпләнгән уртача айлык хезмәт хакының күрсәткечләренә чагыштырмача анализ бер эшчегә хезмәт хакы түләү фонды 19 800 сум булуын күрсәтте, бу Россия Федерациясенең башка субъектлары белән чагыштырганда түбәнрәк (Чувашия Республикасында – 20 707 сум, Түбән Новгород өлкәсендә – 22 908 сум, Самара өлкәсендә – 23 686 сум).

Уздырылган аудит нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына ачыкланган кимчелекләрне бетерү, бюджет чараларын куллануны тикшерүне көчәйтү буенча чаралар күрү өчен мәгълүмати хат, шулай ук тиешле тәкъдимнәр җибәрелде.

«2011-2013 елларга өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш дәрәҗәсен күтәрү» озак вакытка исәпләнгән максатчан программасын тормышка ашыруга, шулай ук картлар һәм инвалидлар интернат-йортларында яшәүчеләр өчен шартлар тудыруга бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит үткәрелде.

2011-2014 еллар өчен программа чараларын финанслауның гомуми күләме 21 177 млн. сум тәшкил иткән, шуларның 90%нан күбрәге – өлкән яшьтәге гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыруга акчалата түләүләр һәм пособиеләр.

Нәтиҗәлелек аудиты барышында 16 районда өлкән яшьтәге гражданнарның социаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм сыйфаты белән канәгатьләнүләрен бәяләү өчен социологик сораштыру үткәрелде. Картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда хезмәт алучы гражданнарның күбесе (92%) социаль хезмәт күрсәтү шартлары белән канәгать.

Татарстан Республикасының өлкән яшьтәге гражданнар өчен стационар учреждениеләр системасы 34 учреждениене, шул исәптән картлар һәм инвалидлар өчен 28интернат-йортны, 6 психоневрология интернатын үз эченә ала.

Тикшерү моментына гомуми профильдәге интернат-йортларга чират юк иде. 2015 елның 1 мартына 102 буш урын бар дип санала иде. Буш урыннар саны арту тенденциясе күзәтелә. Шуның өстенә түләү нигезендә тәкъдим ителгән ятак-урыннар саны да ел саен арта бара.

2011-2014 еллар өчен интернат-йортларны финанслауның гомуми күләме 1,5 млрд. сум тәшкил итте. Финанслау арткан вакытта күрсәтелгән хезмәтләр күләме кими.

2012 елда ремонт эшләре тәмамланган Казандагы 2006 елдан бирле эшләми торган картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортны финанслау тормышка ашырылган. Моннан тыш, эшләми торган котельныйны төзекләндерү һәм газ белән тәэмин итү өчен 3,5 млн. сум акча түләнгән.

Биналарны ягу өчен ел саен «Казан оптика-механика заводы» белән җылылык трассасының бер участогын арендалау өчен килешүләр төзелә.

2012-2014 еллар өчен 1,3 млн. сум акча түләнгән. 2015 елга аренда бәясе 526 мең сумга кадәр үсә. Бюджет чыгымнары аз булганга күрә интернат-йортны җылы белән бәйсез рәвештә тәэмин итү тормышка ашырылмаган.

Аерым интернат-йортларда гомуми күләме 1 700 мең сум булган бюджет чараларын дебитор бурычына тарту, булган ихтыяждан артык акчалар күчерү белән бәйле бухгалтер исәп-хисабын алып баруны бозу фактлары ачыкланган.

Мәсәлән, Казан интернат-йортында «РеаМед» ҖЧҖ күчерелгән 200 мең сум 3 елдан артык дебитор бурычында санала. Буа интернат-йортында 8 контракт буенча китерелмәгән азык-төлек продуктлары өчен гомуми күләме 439 мең сум булган түләү башкарылган.

Күп продуктлар буенча билгеләнгән туклану нормалары һәрвакытта да сакланмый. Корноухово интернат-йортында кош ите һәм балык куллану

нормативның 60-70%ын гына тәшкил иткән, Буа интернат-йортында май, сыр, балык куллану нормативның уртача 80%ын тәшкил иткән.

Тәэминатчыларның үз контракт йөкләмәләрен вакытында үтәмәү фактлары ачыкланган, җитмәсә, заказчылар штраф санкцияләре кулланмаганнар.

Нәтиҗәлелек аудиты нәтиҗәләре буенча әзерләнгән тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр Эксперт советы тарафыннан хупланган. Хисап палатасы тарафыннан ачыкланган бозулар һәм кимчелекләр буенча чаралар күрү өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына күрсәтмә җибәрелде.

«2011-2013 елларга өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш дәрәҗәсен күтәрү» озак вакытка исәпләнгән максатчан программасын тормышка ашыруга, шулай ук картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда яшәүчеләргә шартлар тудыруга бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә үткәрелгән аудит нәтиҗәләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде.

Җибәрелгән бозулар һәм кимчелекләр өчен социаль яклау учреждениеләренең 8 вазыйфаи заты дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү буенча чараларны тормышка ашыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануның **нәтиҗәлелегенә аудит** барышында гомуми күләме 19 351,8 мең сум булган бюджет чараларының нәтиҗәсез файдаланылуы ачыкланган, шул исәптән 16 540,2 мең сум күләмендә дәүләт йөкләмәсен үтәүгә субсидияләр 2 елдан артык файдаланылмыйча калган.

Дәүләт милкен файдаланган вакытта бозулар 44 603,9 мең сум тәшкил иткән, шуларның 35 574,5 мең сумы – милек объектларын, җир кишәрлекләрен исәптә күрсәтмәү формасында.

Учреждениеләрдә тикшерүләр барышында яшәүчеләр саны һәм бер тәрбияләнүчегә туры килә торган мәйдан нормативларын арттыру, йомшак җиһаз һәм туклану нормалары белән тәэмин итү нормаларын сакламау, туклану продуктларын югары бәяләрдән сатып алу фактлары ачыкланды.

Шулай ук бухгалтерлык исәп-хисабының теркәүдә товар-матди байлыкларны күрсәтмәү, хисап мәгълүматларын бозып күрсәтү, бюджет чараларын дебиторлык бурычына юнәлдерү белән бәйле бозулары да табылды.

Учреждениеләр тарафыннан контракт йөкләмәләрен үз вакытында үтәмәүче тәэминатчыларга карата штраф санкцияләре кулланылмаган. Дәүләт контрактлары буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясе аерым очракларда 10%тан артык күләмдә арттырылган. Дәүләт контрактлары буенча хезмәтләрнең контракт төзү датасыннан алда һәм сатулашулар уздырмыйча гына башкарылу фактлары ачыкланган.

Бюджет чараларын файдалануның нәтиҗәлелегенә үткәрелгән аудит нәтиҗәләре буенча хезмәт бурычларын тиешле дәрәҗәдә үтәмәүләре, закон бозуларны булдырганнары, җитешле дәрәҗәдә тикшерү булмавы өчен 2 вазыйфаи зат – балалар йортлары җитәкчеләре дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Аудит нәтиҗәләре турында хисап Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә җибәрелде. Тикшерү материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына тапшырылды.

Татарстан Республикасы торак пунктларын **су белән тәэмин итү һәм су бүлү системалары** төзелеше, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлауга бүлеп бирелгән дәүләт чараларын кулланудың **нәтиҗәлелегенә аудит** нәтиҗәләре буенча 2012-2015 еллар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы торак пунктларын су белән тәэмин итү һәм су бүлү системалары төзелеше, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлауга 2 735,7 млн. сум җибәрелүе ачыкланган.

«Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклау технологияләре һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» ДКУ эшчәнлеген тикшерү тарафыннан су белән тәэмин итү объектлары төзелешенә кертемнәрнең баланс бәясе анализ ясый торган вакыт аралыгы өчен 3 тапкыр артуын һәм 2015 елның 1 сентябренә 2 487,0 млн. сум тәшкил итүен ачыкланды. Фонд балансында 2008 елдан башлап 2012 елга кадәр тәмамланмаган төзелеш составында санала торган объектларның бәясе 743,2 млн. сум тәшкил итә (гомуми күләмнең 29,9%).

Дәүләт контрактлары буенча аванслау лимитларын арттыру, алар буенча хезмәтләр башкару срокларын бозу, шулай ук башкарылган хезмәтләрнең күләмен 3 129,8 мең сумга арттырып күрсәтүнең аерым очраклары ачыкланды.

«Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» эшчәнлеген тикшерү. 2015 елның 23 ноябренә карата су белән тәэмин итү һәм су бүлү системасының чынбарлыктагы бәясе 389,1 млн. сум торган (проект-тикшеренү эшләрен исәпкә алып) 19 объекты 100% әзерлек стадиясендә булуын ачыклый. Күрсәтелгән объектлар учреждение балансында тәмамланмаган төзелеш составында исәпләнә. Чынбарлыктагы бәясе 178,3 млн. сум булган 10 объект эксплуатацияләнә.

Кулланучылар хокукын һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе мәгълүматлары буенча соңгы 3 ел эчендә санитария-химия (10-12%) һәм микробиологик (4-6%) күрсәткечләре буенча билгеләнгән таләпләргә туры килми торган эчә торган су пробалары өлешенең уртача дәрәҗәсе күзәтелә.

Муниципаль районнарның күбесендә торак пунктларны, сууткәргеч челтәрләре белән тәэмин итү белән чагыштырып караганда, канализациянең үзәкләштерелгән челтәрләре белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин итмәү билгеләп үтелә, ә бу торак пунктларның санитария-экология торышына тискәре йогынты ясый. Күп кенә шәһәр һәм бистәләрнең канализация чистарту корылмалары чамадан тыш һәм түбән нәтиҗәлелек белән эшлиләр.

Аерым торак пунктларның җир асты сулары суалгыч корылмаларының оештырылган санитар саклау зоналары юк. Аерым очракларда су белән тәэмин итүнең яңа төзелгән объектлары буенча су пробалары билгеләнгән таләпләргә туры килми.

Нәтиҗәлелеккә уздырылган аудит нәтиҗәләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына җибәрелде. Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклау технологияләре һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фондына ачыкланган бозулар һәм кимчелекләрне бетерү, су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тикшерүне көчәйтү буенча чаралар күрү өчен күрсәтмә җибәрелде.

Тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча җибәрелгән бозулар һәм кимчелекләр өчен Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклау технологияләре һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фондының 4 вазыйфаи заты дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Тикшерү материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенә җибәрелде.

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына **республика халкының мәшгульлегенә ярдәм итүгә** бүлеп бирелгән бюджет чараларын тикшерү кайбер Мәшгульлек үзәкләре булган эш урыннарын саклау һәм яңаларын булдыру, шул исәптән инвалидлар өчен дә, шулай ук эшсез калган гражданнарның үз-үзләрен эш белән тәэмин итүенә ярдәм күрсәтү буенча чараларны тормышка ашырганда җибәргән бозулар һәм кимчелекләрне ачыклады.

Билгеләнгән тәртиптә эшсез калган дип табылган гражданнарга юридик зат, шәхси эшмәкәр яисә крестьян (фермерлык) хуҗалыгы буларак дәүләт теркәве узганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук шундый дәүләт теркәве өчен документлар әзерләгән чакта бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү тәртибен үтәү йөзеннән гражданнарга бирелә торган Мәшгульлек үзәкләре тормышка ашыра торган субсидияләрне сарыф итүне тикшерү тиешле дәрәҗәдә оештырылмаган.

Гражданнар тарафыннан алынган чараларны тоту, субсидияләнә торган эшмәкәрлек эшчәнлеген тормышка ашыру турындагы мәгълүматны бирү тәртибе үтәлмәгән.

Инвалидлар өчен эш урыннары оештырганда бюджет чараларын башбаштакларча тоту мөмкинлеге туган. Тиешле Исемлектә әлеге чыгымнар рәсмиләштерелмәгән. Нәтиҗәдә эш бирүчеләр инвалидлар өчен махсуслаштырылган шартлар булдыру белән бәйле булмаган чыгымнарны каплый. Тикшерүләр барышында җитештерү өчен кирәкле материаллар сатып алуга, офисларны тәртипкә китерү һәм башкаларга чыгымнарны компенсацияләү фактлары ачыклана.

Моннан тыш, Мәшгульлек үзәкләрендә гомуми күләме 6 408,4 мең сумлык хисап мәгълүматларын бозып күрсәтү, бухгалтерлык исәбен алып бару, күчемсез милеккә милек хокукын теркәү булмау белән бәйле булган финанс бозулары ачыкланган.

Ачыкланган бухгалтерлык һәм бюджет хисаплылыгын бозулар очраклары буенча директор һәм бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы – социаль яклау учреждениесе баш бухгалтеры 4 мең сум штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылды.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелгән дәүләт контрактлары вакытларын бозып 1 573 мең сумга оргтехника белән тәэмин итү тормышка ашырылу ачыкланган. Шуның өстенә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы килешү йөкләмәләрен үтәүнең вакытын уздырып җибәрү өчен тәэминатчыдан неустойка (килешү шартларын үтәмәгән өчен түләнә торган штраф) түләтү хокукыннан файдаланмаган.

Россия Федерациясе Бюджет классификациясен куллану тәртибе турында гамәлдәге күрсәтмәләрен бозып, гомуми күләме 206,5 мең сумга адреслы папкалар, сувенир һәм бүләк продукцияләре сатып алу буенча чыгымнар тотылган.

Тикшерү барышында дәүләт милкен файдалану белән бәйле гомуми күләме 276 мең сум булган кимчелекләр ачыкланган. Шулай итеп, гомуми бәһасы 59 мең сум булган республика бюджет чаралары исәбенә алынган 3 сканер, алар 2014 елда мировой судьялар аппараты эшчәнлеген тәэмин итүгә бүлеп бирелә, чынбарлыкта министрлык балансына куела һәм тикшерү моментына аның бүлекчәләрендә файдаланыла.

Россия Федерациясенең Гражданлык кодексының 131 маддәсен бозып, министрлык тарафыннан муниципаль районнарда мировой суд биналары биләгән 5 җир кишәрлегенә милек хокукы рәсмиләштерелмәгән. Шулай ук тикшерү барышында муниципаль районнарда мировой судлар урнашкан һәм балансларында булган 38 бинаның Министрлыкка оператив идарә итүгә тапшыру турында таныклыклар тәкъдим ителмәгән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык тарафыннан тәэминатчыга килешүне үз вакытында үтәмәгән өчен штраф санкцияләре түләү турында дәгъва хаты җибәрелде.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында тикшерү аерым очракларда барлыкка килгән дебиторлык бурычы күләме Министрлыкның хезмәт күрсәтүләрдә икееллык ихтыяҗыннан артып китүе ачыкланган, күрсәтелмәгән хезмәтләр өчен тәэминатчыларга барлыгы 4 186, 4 мең сум акча түләнгән.

Министрлык балансында озак вакыт эчендә (4 елдан артык) гомуми күләме 51 684,2 мең сум булган тәмамланмаган төзелеш объектлары саналган, тикшерү вакыты аралыгында аларны финанслау тормышка ашырылмаган.

Дәүләт заказлары буенча йөкләмәләрне үтәгәндә бозулар ачыкланган. Контрактларны үтәү срокларын бозган өчен җаваплылык чаралары кулланылмаган. Тикшерү моментына вакытында үтәлмәгән контрактлар буенча неустойканы исәпләү күләме 6 191,3 мең сум тәшкил итә.

Тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча Министрлыкка ачыкланган бозулар һәм кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрү өчен күрсәтмә җибәрелде. Тикшерү материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлланды.

Министрлык тарафыннан гомуми күләме 82 886,3 мең сум булган ачыкланган бозулар һәм кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрелде, оешмалар дәүләт контрактлары буенча йөкләмәләрне үтәү вакытларын бозган өчен неустойка түләделәр.

2013-2014 елларда **Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләренең техник торышына күзәтчелек итү идарәсенә** (алга таба – Идарә) бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджет чараларын куллануны тикшерү, керемнәр администраторы функцияләрен үтәү нәтиҗәләре буенча бюджет чараларын кулланганда нәтиҗәсез эшчәнлек, исәптә товар-матди байлыкларының булмавы, финанс хисаплылыгын бозып күрсәтү белән бәйле бозулар ачыкланды.

Тикшерү анализлана торган вакыт аралыгында исәпкә куелган үзйөрешле техниканың саны 71 берәмлектән 78 гә кадәр артканлыгын күрсәтә. Шуның белән бергә, теркәлгән үзйөрешле техниканың гомуми санына карата 39 %ының эксплутацияләнүгә рөхсәте юк.

Ачыкланган бозуларның гомуми күләме 24 178,9 мең сум тәшкил итә, аларны юкка чыгару буенча 21 944,7 мең сумга чаралар күрелгән.

Идарә дәүләт техник карау, тракторларны, үзйөрешле һәм башка машиналарны теркәү үткәрүдән, таныклыклар бирүдән Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең администраторы, шулай ук шәһәр округлары һәм муниципаль районнар бюджетларына күчерелә торган

акчалата түләтүләр (штрафлар) һәм зыянны каплау өчен башка суммалардан кертемнәр буенча керемнәр администраторы булып тора.

Тикшерелгән вакыт аралыгы өчен 1 429 боерык рәсмиләштерелә, машинадан файдаланганда бозулар һәм дәүләт техник каравына китермәү өчен 1 852 штраф салына, үзйөрешле техника һәм җиһазларны эксплуатацияләүне тыя торган 349 акт төзелә.

Шуның өстенә, гамәлдәге законны бозып, Бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен тормышка ашыру тәртибе эшләнмәгән. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына керә торган исәпләнгән түләттерелгән акча күләме һәм зыянны каплауның башка бәяләре Идарә исәп-хисабында чагылыш тапмаган.

14 768 мең сумлык күчемсез милек объектлары милек хокукын мәҗбүри дәүләт теркәве үтмәгән.

Киләсе ел өчен аванс түләүләрен күчерү, чынбарлыкта биләгән мәйданнардан артык коммуналь хезмәтләр өчен түләү нәтиҗәсендә 1 362,5 мең сумлык бюджет чаралары куллануның нәтиҗәлелеге тәэмин ителмәгән.

Исәптә администрацияләнгән табышлар керүен чагылдырмау, исәптә товар-матди байлыкларның булмавы белән бәйле бухгалтерлык исәбен алып баруны бозулар 8 043,1 мең сум тәшкил иткән.

Ачыкланган бухгалтерлык һәм бюджет хисаплылыгын бозулар факты буенча Идарә башлыгы һәм бухгалтерлык исәбе, финанслаштыру һәм анализ бүлеге башлыгы гомуми күләме 8 мең сум булган штраф формасында административ җаваплылыкка тартылды.

Татарстан Республикасында аерым категория гражданнарга **теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтүгә** бүленгән бюджет чараларын файдалануны тикшерү мондый хезмәтләрне сәламәтлек саклауның төрле типтагы һәм буйсыну дәрәҗәсендәге 62 оешмасы тормышка ашырганлыкны күрсәтте.

Татарстан Республикасында аерым категория гражданнарга теш протезлары һәм колак аппаратлары кую буенча хезмәт күрсәтүләрнең еллык программаларын финанслауның гомуми күләме 2013-2014 еллар өчен 179 млн. сум тәшкил итә.

Шуның өстенә ел саен медицина учреждениеләренең программа чараларын тулы күләмдә үтәмәүләре хисабына барлыкка килгән үзләштерелмәгән чаралары кала килгән. Медицина учреждениеләре арасында

чаралар калдыкларын үз вакытында яңача бүлү льготалардан файдаланучыларның өстәмә санына хезмәт күрсәтү мөмкинлеген биргән булыр иде.

Тикшерү чарасы нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фондына җибәрелде. Тикшерү материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлланды. Шәһәрләр һәм районнар прокуратура органнары тарафыннан протезлау буенча хезмәт күрсәтә торган сәламәтлек саклау учреждениеләренә ачыкланган бозуларны алга таба җибәрмәү турында күрсәтмәләр җибәрелде, гаепле затлар дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсендә тикшерү (алга таба – Татарстан Республикасы БИТИ) тәмамланмаган төзелеш күләмнәрен киметү, объектларны муниципаль берәмлекләргә (эксплуатацияләүче оешмаларга) тапшыруның билгеләнгән тәртибен саклау, капиталь салымнар объектлары буенча файдаланылмаган чаралар калдыклары барлыкка килүнең нигезлелеге буенча күрелә торган чараларның нәтиҗәлелеге мәсьәләләре буенча уздырылды.

Тикшерү финанс булмаган активларга кертемнәр бәясе 2012 елның 1 гыйнваренә карата 21 896,7 млн. сум, 2013 елның 1 гыйнваренә – 22 438,6 млн. сум, 2014 елның 1 гыйнваренә – 24 989,1 млн. сум, 2015 елның 1 гыйнваренә 33 578,6 млн. сум тәшкил итүен күрсәтте.

Бухгалтерлык исәбен алып баруның билгеләнгән тәртибен, милекне инвентаризацияләү үткәрүне, объектларны эксплуатацияләүче оешмаларга тапшыруны бозулар ачыкланды.

Тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы БИТИна – күрсәтмә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына – мәгълүмат, Татарстан Республикасы Прокуратурасына тикшерү материаллары җибәрелде.

Татарстан Республикасы БИТИ тарафыннан күрсәтмәне үтәү йөзеннән бухгалтерлык исәбен тәртипкә салу һәм аның дөреслеген тәэмин итү буенча чаралар кысаларында исәпкә алу язмаларын һәм бюджет исәбенең 106 «Финанс булмаган активларга кертемнәр» счеты буенча калдыкларны инвентаризацияләү уздырылган. Инвентаризацияләү нәтиҗәләре буенча

гомуми күләме 550 017 мең сум булган муниципаль берәмлекләргә тапшырылган 33 объект буенча исәпкә алу язмалары төгәлләштерелгән.

Бюджет чараларын файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм дәүләт (муниципаль) милкенең сакланышын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы БИТИ тарафыннан заказчысы Татарстан Республикасы БИТИ булган Татарстан Республикасы бюджет чаралары хисабына төзелгән (сатып алынган) күчемсез милек һәм күчемле милек объектларын үз вакытында тапшыруны тәэмин итүне күздә тота торган Татарстан Республикасы БИТИ, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары һәм дәүләт оешмаларының үзара хезмәттәшлеге турында регламентны раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты эшләнде.

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – Агентлык) бүлеп бирелгән бюджет чараларын тикшерү 33 261,1 мең сумлык бозуларны ачыклады. Шуларның хисаплылыкны бозып күрсәтү, товар-матди байлыкларны керемгә язып куймау белән бәйле бухгалтерлык исәбен алып баруны бозулар 32 069,4 мең сум тәшкил итте.

663,6 мең сум күләмендәге бюджет чараларын файдалануның нәтиҗәлелеге тәэмин ителмәгән. Шулай итеп, 2013 елның гыйнвареннән августына кадәр Агентлык «Татмедиа» АҖнән Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорты адресы буенча урнашкан бинаның 3 һәм 4 катларындагы бүлмәләрне арендалаган. Эксплуатация буенча чыгымнар аренда бәясенә кергән. Шуның белән бергә, йортның эчке территорияләрен һәм гомуми кулланыштагы урыннарны арендалауга килешүләр булмаганда алар биләмәгән биналарны җыештыру өчен 205,9 мең сумга чыгымнар тотылган.

Модернизацияләү, мәгълүмат урнаштыру, www.antinarc.ru сайтында веб-вәкиллек әзерләү буенча эшләр башкару өчен 446 мең сум акча түләнгән. Тикшерү вакытына сайтка керү мөмкинлеге юк иде.

Уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы адресына бозуларны юкка чыгару һәм чаралар күрү өчен күрсәтмә җибәрелде.

Агентлык тарафыннан гомуми күләме 32 070,9 мең сум булган ачыкланган бозуларны юкка чыгару буенча чаралар күрелде. Кулланылмаган җиһазлар эксплуатациягә кертелде, www.antinarc.ru «Антинарк. Наркоманиягә

каршы тору буенча Татарстан Республикасының мәгълүмати порталы» сайтының эше торгызылды.

Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру, каникул вакытында аларның мәшгульлеген тәэмин итү, сәламәтләндерүнең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча кирәк булган шартларны тудыру өчен 2012-2013 еллар вакыт аралыгы өчен еллык программалар белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы бюджетыннан 971 808,9 мең сум бүлеп бирелә.

Программалар чаралары координаторы булып Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тора.

«Җәй» Республика балалар һәм яшьләрнең сәламәтләндерү, ялын һәм мәшгульлеген оештыру буенча үзәге» ДБУн тикшерү барышында 2011 елның 6 декабрендә кул куелган 402-ФЗ номерлы «Бухгалтерлык исәбе турында» Федераль законының 9 маддәсе таләпләрен беренчел бухгалтерлык документациясен рәсмиләштерү өлешендә (тиешенчә рәсмиләштермәгән документлар буенча транспорт хезмәтләренә түләү башкарылган) 377,6 мең сумлык бозулар ачыклана.

Моңардан тыш, «Пионер», «Акчарлак», «Ялкын» һәм «Хыял» балалар сәламәтләндерү лагерьларында медицина эшчәнлеге тиешле лицензиядән тыш башкарылган. Медицина эшчәнлегенә лицензиясе булмаган 4 балалар сәламәтләндерү лагере медицина хезмәткәренә хезмәт хакы түләү 830,6 мең сум тәшкил иткән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча «Ялкын» һәм «Хыял» балалар сәламәтләндерү лагерьлары җитәкчеләре дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Казан шәһәренең Вахитов районы прокуратурасы тарафыннан Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы адресына балигъ булмаган балаларның сәламәтлеген саклау турында законнарны бозуларны бетерү турында күрсәтмә җибәрелде.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының **Республика клиник тире-венерология диспансеры**» Дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының **Республика клиник офтальмология хастахәнәсе**» Дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә бүлеп бирелгән Республика бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина

иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты чараларын файдалануны тикшерүләр гомуми күләме 45 847,8 мең сум булган бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгын алып баруны бозу очракларын ачыклаган.

Республика клиник тире-венерология диспансеры тарафыннан амортизация күчерүләре нормаларын ялгыш куллану нәтиҗәсендә аның балансында тора торган төп чараларның калган кыймәте 23 600 мең сумга төшереп күрсәтелгән, бу бюджет системасына милеккә салым гомуми күләме 518,8 мең сум булган чара күчерелеп бетмәүгә китергән.

Республика клиник тире-венерология диспансеры Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгы таләпләрен дәвалау туклануы нормаларын саклау өлешендә үтәүне тәэмин итмәгән. Шулай итеп, Түбән Кама филиалы буенча 2015 елның беренче ярты еллыгы өчен дәваланучылар тарафыннан ярмалар куллану норматив күрсәткечтән 108%, балык – 82%, яшелчәләр – 84% тәшкил иткән.

Яр Чаллы шәһәренең 11 номерлы хастаханәсенең 2 055 кв. метрлы

төзелеп бетмәгән дүрт катлы бинасы 2013 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте боерыгы буенча «Республика клиник тире-венерология диспансеры» ДАССУнә тапшырыла.

Бинаны эксплуатациягә яраклы хәлгә китерү һәм аны хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү буенча чаралар күрелми.

Тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча җибәрелгән бозулар һәм кимчелекләр өчен сәламәтлек саклау учреждениеләренең 4 вазыйфаи заты дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Табиб рецептлары буенча **өч яшькә кадәрге балаларны балалар туклануының махсус продуктлары белән тәэмин итүне тормышка ашыруга** бүлеп бирелгән бюджет чараларын файдалануны тикшерү нәтиҗәләре буенча балалар туклануына рецептлар бирү һәм рәсмиләштерү процедурасын бозулар ачыклана (табибларның имзалары һәм шәхси мөһерләре булмый). Аерым очракларда сөт продуктлары язылган рецептлары булмаганда да бирелә.

Аерым очракларда бүлү пунктларында суыту җиһазлары булмый яисә китерелә торган продукциянең барысы да сыеп бетми. Саклау температурасы режимын бозып, балалар тукланыуы продуктлары идәнгә, өстәлләргә куела.

Балалар ризыкларын тикшерелгән район үзәк хастаханәләренең тарату пунктларыннан амбулаторияләргә һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларына китерү сөт продуктларын ташуга яраклаштырылмаган ашыгыч ярдәм машиналарында, таксида, шәхси машиналарда башкарылган.

Аерым очракларда амбулаториядә һәм фельдшерлык-акушерлык пунктларында балалар ризыкларын бушату накладнойлар белән рәсмиләштерелмәгән. Тарату пунктларында ата-аналар алып бетермәгән сөт продуктларының калдыклары сакланган. Югыйсә, бухгалтерлык исәбендә продукциянең калуы турында документлар юк.

Кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе тарафыннан Казан шәһәренең һәм Татарстан Республикасының дәвалау-профилактикалау учреждениеләрендә балалар ризыгын саклаганда һәм урнаштырганда техник регламент таләпләрен бозу очраклары буенча сәламәтлек саклау учреждениеләренең 10 вазыйфаи заты 50 мең сум күләмендәге штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылды.

Татарстан Республикасының «Татаркино» Дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Мир» кинотеатры өчен кәнәфиләр сатып алуга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын файдалануны тикшерү барышында «Каскад» ПК ҖЧҖ белән электрон аукцион нәтиҗәләре буенча гомуми бәясе 450 мең сумлык контракт төзелгәнлеге ачыкланды.

Дәүләт контрактын урнаштыру һәм үтәү вакытында 2013 елның 5 апрелендә кул куелган 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләрне тәэмин итү өчен товарлар, хезмәтләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законының китерелгән

товарның техник бурычның аерым характеристикаларына туры килмәү өлешендә таләпләрен бозу билгеләре ачыкланды. Шул ук вакытта контрактның бәясе киметелмәгән.

Тәэминатчыны ачыклау нәтиҗәләре буенча дәүләт контракты билгеләнгән шартларны сакламыйча төзелгән. Контрактка товар характеристикаларын үз эченә алган махсуслаштыру юк, шулай ук бердәм мәгълүмати системада документларны (контрактның заказчысы имзалаган контракт проекты, дәүләт контрактын үтәү турында хисап) урнаштыру вакытлары да бозылган.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча мәгълүмат Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенә җибәрелде, җавап чаралар күрү өчен мәгълүмат Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына юлланды.

2015 елда **Азнакай, Буа, Яшел Үзән, Лениногорск, Түбән Кама, Минзәлә, Питрәч һәм Теләче** муниципаль районнарында комплекслы тикшерү чаралары уздырылды.

Комплекслы тикшерүләрдән тыш, 10 муниципаль районда биологик калдыкларны һәм чүп-чарны сортларга аеру линияләре өчен күчмә мобиль җайланмалар алуга бүлеп бирелгән бюджет чараларын файдалануны, туклану продуктлары сатып алуга җибәрелгән бюджет чараларын куллануны һәм башка мәсьәләләр буенча тематик тикшерүләр уздырылды.

Муниципаль районнарда үткәрелгән комплекслы тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча гомуми күләме 764 119,9 мең сум булган бозулар табылды, шул исәптән:

- муниципаль милек һәм җир кишәрлекләре белән эш йөрткәндә һәм идарә иткәндә бозулар – 432 817мең сум;
- «Бухгалтерлык исәбе турында» Федераль законны, исәп һәм хисап мәсьәләләрен көйләүче башка норматив хокукый актларны бозулар – 201 556,3 мең сум;
- бюджет чараларын нәтиҗәсез файдалану – 48 178,5мең сум;
- бюджет чараларын максатсыз файдалану – 2 119,1мең сум;
- башка бозулар (энергетика ресурслары өчен түләүгә бюджет чараларын нормативтан артык чыгымга чыгару, бюджет югалтулар,

җирле бюджетка өстәмә йөкләмә, төзелеш-монтаж эшләренең бәясен арттырып күрсәтү – 79 449 мең сум.

Җир һәм милек мөнәсәбәтләре өлкәсендә ачыкланган бозуларның күпчелеге башлыча аренда килешүләре буенча акча чараларының кереп бетмәве, тапшырылган объектлар өчен вакыты узган бурычлар булуы, милекне нәтиҗәсез файдалану белән бәйле.

Теләче муниципаль районында тикшерү чарасын уздыру вакытына казна милке составында гомуми бәясе 2 600 мең сум булган 2014 елда ук шәхси кешеләргә сатылган төп чаралар (вертикаль резервуар, минераль порошок склады, асфальт җәйгеч) санала.

Буа муниципаль районында хокук раслаган документлардан башка эксплуатацияләүче оешмаларга гомуми бәясе 14 млн. сумнан артык булган коммуналь хуҗалык объектлары (канализация челтәрләре һәм Буа шәһәрендәге кертү газүткәргече – «Буа Водоканал» АӘҖ һәм «Таттрансгаз» ҖЧҖ эксплуатацияләүче оешмаларына) тапшырылган.

Питрәч муниципаль районының башкарма комитетында бәясе 38 146 мең сум булган торак-коммуналь объектлары (су белән тәэмин итү, канализация, газ белән тәэмин итү челтәрләре) саналган. Чынбарлыкта күрсәтелгән объектлар халыкка коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен коммерциячел оешмалар тарафыннан файдаланылган. Шул вакытта муниципаль милек иясе һәм коммерциячел оешмалар арасында тиешле килешү мөнәсәбәтләре ачыкланмаган.

Минзәлә муниципаль районында районда җирләрне арендалаган өчен арендаторларның вакыты узган бурычлары 2 100 мең сум тәшкил итә.

Минзәлә районы Тауасты Байлар авыл җирлегендә ындыр табагы, орлык склады

Тауасты Байлар авыл җирлегендә производство корылмаларының бер өлешен (ындыр табагы, орлык склады һәм башкалар), аренда килешүләре төземичә, чынбарлыкта коммерциячел предприятиеләр файдалана. Нәтиҗәдә, авыл җирлеге 374 мең сумлык аренда түләвен алып бетермәгән. Тикшерү барышында кирәкле аренда килешүе төзелде.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль районнар территорияләрендә урнашкан киң таралган файдалы казылмаларны табу буенча санкцияләнмәгән карьерлар эшләү фактлары ачыкланды.

Минзәлә муниципаль районында Урус авылы һәм «Воровский исемендәге совхоз» янындагы карьерларда ком, Тауасты Байлар авылыннан төньяк-көнчыгыштарак – балчык, Наратлы Кичү авылыннан төньяктарак карбонат токымнары чыгарылган.

Минзәлә муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендәге карьерлар (Воровский исемендәге бистә һәм Тауасты Байлар авылы)

Лениногорск муниципаль районында Зәй-Каратай, Горка, Конгоровка, Сугышлы, Глазово, Югары Чыршылы, Урмышлы, Югары Каран, Савочкино торак пунктлары янында ком, вак таш чыгару буенча 11 санкцияләнмәгән карьер ачыкланган.

Питрәч муниципаль районында «Горняк» ҖЧҖнә авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен җир кишәрлеген арендалау килешүе буенча 6,5 га мәйданлы җир кишәрлеге арендага бирелгән. Тикшерү чынбарлыкта әлеге кишәрлектә известьташ чыгарылуын ачыклады. Күрсәтелгән җир кишәрлеген башка категория җиргә күчерүне раслаган документлар тикшерүгә тәкъдим ителмәде.

Тикшерү материаллары Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына һәм Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәте Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырылды.

2015 елның июнендә сатулашулар йомгаклары буенча физик затка 4 279 кв. метр мәйданлы 3 кишәрлек 1 988,9 мең сум еллык аренда түләве белән арендага бирелә. Ул 2015 елның декабрендә кишәрлекләрне, әлеге кишәрлекләрдә урнашкан корылмалар милекчесе буларак, 14,6 мең сумга хосусыйлаштыра.

Шулай итеп, җир кишәрлекләрен аренда килешүләре буенча чынбарлыкта файдалану 6 ай тәшкил итә.

Питрәч муниципаль районының Гильдеево авылындагы җир кишәрлекләрендә төзелгән һәм теркәлгән объектлар

Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, хезмәт һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә бозулар башлыча төзелгән контрактларның китерү вакытларын саклау, товарларның сыйфаты, бәясе һәм ассортименты өлешендә шартларны нигезсез үзгәртүләр, аларны үтәү вакытларын бозган өчен неустойка түләтү буенча чаралар күрелмәү белән бәйле.

Азнакай муниципаль районының белем бирү учреждениеләренә товар-матди байлыклар китерү буенча килешү йөкләмәләрен үтәлешен тикшерү 2014 елның октябреннән бирле Азнакай шәһәренең Балалар иҗаты үзәгенә гомуми күләме 1 102 мең сум булган акчасы түләнгән 13 профориентация тренажерының китерелеп җиткерелмәвен ачыклаган. Тикшерү барышында 1 053 мең сумлык тренажерлар китерелгән.

Азнакай шәһәрендәге Балалар иҗаты үзәгенә китерелгән профориентация тренажерлары

Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан юл эшләрен үтәүгә контрактлар үтәлешенең вакытларын бозган өчен гомуми күләме 441,3 мең сум булган неустойка түләтү буенча чаралар күрелмәгән.

Шулай итеп, «РусРемСтрой» ҖЧҖ белән җирле әһәмияткә ия гомуми кулланылыштагы юлларда юл эшләре муниципаль программаларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән эшләрне башкаруга гомуми күләме 19 303 сум булган муниципаль контракт төзелгән. Эшләрне башкару вакыты 2014 елның 1 сентябренә кадәр дип билгеләнгән. Чынбарлыкта хезмәтләр вакытны 56 көнгә кадәр бозып башкарылган.

Буа, Спас муниципаль районнарында һәм «Идель» Республика инвалидларны социаль тернәклендерү үзәге» ДБУ дә тикшерү чаралары барышында балаларга мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә һәм картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларда сыйфатсыз сыер мае белән тәэмин итү фактлары ачыкланган. Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге тикшеренүләре беркетмәләре «Сөт һәм сөт продуктларының куркынычсызлыгы турында» Техник регламенты таләпләрен бозылуны раслый.

Минзәлә Үзәк район хастаханәсендә авыруларны туклану продуктлары белән тәэмин итү буенча контрактларны үтәгәндә аерым бозулар җибәрелгән. Төзелгән контракт спецификациясенә туры килми торган продуктлар китерү очраклары булган.

Бюджет чараларын һәм милкен нәтиҗәсез файдалану фактлары ачыкланган.

Теләче муниципаль районы башкарма комитеты 1 516 мең сум җирле бюджет чараларын 8 Себер язвалы терлекләр каберлеге һәм 14 биотермик чокыр коймаларын ремонтлау буенча эшләр башкаруга җибәрелгән. Әлеге

объектларны карау вакытында төзелгән контрактлар һәм килешүләр белән каралган хезмәт күләме периметрларны өлешчә киртәләүне генә тәэмин итүе ачыкланды. Күпчелек очракта яңа коймалар бары тик дүрт якның икесендә генә бар. Яхшы сыйфатлы койма булмау һәм потенциаль куркыныч объектларга ирекле кереп йөрү мөмкинлеге булу сәбәпле, йогышлы авыруларның таралу куркынычы саклана.

Олы Мәтәскә авылында биотермик чокыр коймасына ремонт

Түбән Савруш авылында терлекләр каберлеге коймасына ремонт

Табигатьне саклау чаралары кысаларында бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү 2008-2010 елларда алынган гомуми күләме 28 827,3 мең сум булган чүп-чарны сортларга бүлү линияләрен, биологик калдыкларны утилизацияләү буенча корылмаларның нәтиҗәсез файдалану һәм кирәк булмаганлыгы фактларын ачыклады. Сатып алынган 86 корылманың гомуми кыймәте 19 021,6 мең сум булган 60 берәмлеге эксплуатацияләнмәгән.

Файдаланылмый торган чүп-чарны сортларга бүлү линияләре һәм биологик калдыкларны утилизацияләү буенча корылмалар

Мәсәлән, Нурлат муниципаль районында корылмаларның берсе 2008 елда районның Башкарма комитеты башлыгы боерыгы буенча «Нурлатпродукт» ҖЧҖ нә бирелә. 2014 елда «Нурлатпродукт» эшчәнлеген туктата, 330 мең сумлык корылма кире кайтарылмый. Хәзерге вакытка аның кайдалыгы ачыкланмады.

Бөгелмә муниципаль районында Карабаш ш.т.б. муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты балансында санала торган 330 мең сумлык биологик калдыкларны яндыру буенча корылма чынбарлыкта юкка чыккан.

Әлеге фактлар буенча тикшерү материаллары Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенә җибәрелде.

Бөгелмә муниципаль районында Карабаш ш.т.б. муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә карата Россия Федерациясе Җинаять кодексының 160 маддәсе 3 бүлеге буенча җинаять эше кузгатылды.

Питрәч муниципаль районы Башлыгы карары белән 2013 елда 11 берәмлек персонал кыскартылган. Барлыкка килгән экономия калган хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыруга яңадан бүленгән.

Шуның белән бергә, 2013 елда районның башкарма комитеты «Капиталь төзелеш үзәге» МУП белән персонал хезмәтләре күрсәтүгә килешү төзегән. Чынбарлыкта әлеге килешүләр буенча элегрәк кыскартылган хезмәткәрләрнең хезмәт функцияләрен үтәү буенча хезмәт күрсәтүләр алынган.

Шундый ук хәл 2014 һәм 2015 елларда да сакланган. Районның башкарма комитетының «Капиталь төзелеш үзәге» МУП белән төзелгән килешүләр буенча районның 19 берәмлекле Башкарма комитеты хаҗәтләре өчен персонал хезмәт күрсәтүләре өчен 2014 елда 3,5 млн. сум акча түләнә. 2015 елда «ДСК «Прогресс» ҖЧҖ белән төзелгән контракт буенча 2,3 млн. сум, «Капиталь төзелеш үзәге» МУП – 2 млн. сум түләнә.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, район Башкарма комитетының хезмәткә түләүгә чыгымнары ел саен арта бара. Шулай итеп, хезмәт өчен түләүгә чыгымнар өстәмә исәпләмәләре белән 2013 елда – 9,5 млн. сум, 2015 елда 11,8 млн. сум тәшкил итә.

Моннан тыш, районның Башкарма комитеты чынбарлыкта кыскартылган хезмәткәрләрнең хезмәт функцияләрен башкарган затлар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү буенча түләү килешүләре буенча 8,6 млн. сум күләмендә чыгым тоткан.

2011 елда Теләче авыл җирлеге милкенә бирелгән гомуми бәһасы 7 730 мең сум булган 2006 елда төзелгән чистарту корылмалары эксплуатацияләнмәгән, тикшерү көнендә дә файдаланылмаганнар, аларны карап тоту буенча тиешле чаралар күрелмәгән.

Азнакай муниципаль районының Актүбә ш.т.б. Башкарма комитеты скважина бораулау һәм чүп-чар ташучы машина алу өчен гомуми күләме 2 956,7 мең сум булган чыгым тоткан, әмма алар тикшерү вакытына файдаланылмаганнар.

Түбән Кама, Минзәлә һәм Теләче муниципаль районнарында үткәрелгән тикшерү чаралары гомуми суммасы 2 119,1 мең сум булган бюджет чараларын максатсыз куллану фактларын ачыклаган.

Теләче муниципаль районының «Алан гомуми урта белем бирү мәктәбе» МББББУ мәктәпкә ремонт үткәрү буенча чынбарлыкта башкарылмаган эшләр өчен гомуми күләме 102,7 мең сум булган түләү башкарган. Тикшерү барышында подрядчы (*«Цереком» ҖЧҖ*)җирле бюджетка әлеге чараларны керткән.

Административ хокук бозу факты буенча Алан гомуми урта белем бирү мәктәбе» МББББУнә 10,3 мең сум күләмендә административ штраф салынган.

Минзәлә шәһәрендә «Капиталь төзелеш идарәсе» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан 2014 елда чынбарлыкта шәһәр паркында асфальт каплама салу буенча башкарылмаган хезмәтләргә түләү нәтиҗәсендә 541мең сум күләмендә җирле бюджет чараларын максатсыз файдалану җибәрелгән. Тикшерү барышында подрядчы (*«Чиста шәһәр» ҖЧҖ)* әлеге хезмәтләрне башкарган.

Административ хокук бозу факты буенча «Капиталь төзелеш идарәсе» МКУ һәм аның җитәкчесе гомуми күләме 47,1 мең сум булган штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы 2015 елда үткәргән тикшерү нәтиҗәләре буенча бюджет чараларын файдаланганда, республика, муниципаль милектән файдаланганда җибәрелгән бозулар һәм башка финанс бозуларын бетерү буенча гомуми күләме **2 056 006,2** мең сум булган **чара күрелгән** (бозуларның гомуми күләменә карат 88,5%).

Министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләренә, муниципаль район башлыкларына ачыкланган бозулар буенча **60 күрсәтмә** һәм **мәгълүмати хат** җибәрелде.

Барлык тикшерү чаралары материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына тапшырылды.

Шәһәр һәм республика районнары прокурорлары тарафыннан башкарма хакимият, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре адресына бюджет законнарын бозуларны юкка чыгару турында таләпләр белән **65 күрсәтмә** җибәрелде.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм прокуратура органнары күрсәтмәләре буенча **151 вазыйфаи зат** дисциплинар җаваплылыкка тартыла, **4 вазыйфаи зат** вазыйфаларыннан азат ителде.

Хисап палатасы вазыйфаи затлары, Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары, Яр Чаллы шәһәре, Алексеевский, Азнакай, Лениногорский, Минзәлә, Питрәч, Теләче муниципаль районнары мировой судьялары һәм Екатеринбург шәһәре Югары Исет районының 2 нче номерлы Суд участогы мировой судьясы тарафыннан төзелгән беркетмәләрне карау нәтиҗәләре буенча бухгалтер исәбен һәм бюджет хисаплылыгын алып баруны тупас бозулары өчен гомуми күләме **151,4 мең** булган штраф рәвешендә административ җаваплылыкка **38 вазыйфаи зат һәм 2 юридик зат** тартылды.

Республика прокуратурасы органнары карарлары белән «ФОН» ЯАҖ генераль директоры Ливада А.Н. («Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсе буенча – **40 мең сум** күләмендә) һәм Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан «Забава» катнаш төрдәге 106 номерлы балалар бакчасы» МАМБУ мөдире (һәркем өчен бушлай булган мәктәпкәчә белем алуга бүлеп бирелгән бюджет чараларын максатчан һәм нәтиҗәле куллануны тикшерү нәтиҗәләре буенча – **30 мең сум** күләмендә) штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылган.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы тарафыннан табигатьне саклау һәм җир законнарын бозган өчен «СтройИнвест» КМК ҖЧҖ **60 мең сум** күләмендә административ штрафка тартылды.

Кулланучылар хокукын һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 10 вазыйфаи зат гомуми күләме **50 мең сум** күләмендә штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылган (табиблар

рецептлары буенча өч яшькә кадәрге сабыйларны балалар туклануы өчен махсус продуктлар белән тәэмин итүне оешытруга бүлеп бирелгән чараларны куллануны тикшерү нәтиҗәләре буенча).

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 9 вазыйфаи зат гомуми күләме **11 мең сумлык** штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылган («Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча).

2015 елда үткәрелгән тикшерү чаралары буенча йомгаклау документлары Хисап палатасының мәгълүмати бюллетеньнарында басылып чыкты, шулай ук Хисап палатасының рәсми сайтында (http://www.sprt.tatar) урнаштырылды.

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек

Хисап чорында Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, региональ тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлекне үстерү һәм ныгыту буенча эш үткәрелде.

2015 елның гыйнвар аенда Россия Федерациясе Хисап палатасы Коллегиясенең киңәйтелгән утырышы булып узды, ул тышкы финанс тикшерүе органының 20 еллык юбилеена багышланды. Анда Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин, Россия Федерациясе Федераль җыелышы, Россия Федерациясе Президенты администрациясе җитәкчеләре,

парламент фракцияләре лидерлары, Россия Хөкүмәте әгъзалары, Россия Федерациясе тикшерү һәм финанс органнары җитәкчеләре, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы Президиумы әгъзалары, аның

составына Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе Алексей Демидов та керә, катнаштылар.

Россия Хисап палатасы Рәисе Татьяна Голикова ведомствоның соңгы елларда куелган төп бурычны үтәвен билгеләп үтте: финанс тикшерүеннән аудитка күчү уңышлы булды. Хисап палатасы эш нәтиҗәләре бюджетны планлаштыруның сыйфатын үстерү һәм федераль бюджетның үтәлешен оештыруның, бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенең шактый резервлары булуын раслый.

Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы Хисап палатасы тышкы дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүенең 2 типовой стандартын: «Россия Федерациясе субъекты (муниципаль берәмлек) бюджетын үтәүне оператив тикшерү» һәм «Финанс аудитын үткәрү һәм нәтиҗәләрен теркәү») эшләде.

Шулай ук белгечләр тикшерү эшчәнлегенең актуаль юнәлешләре буенча Тышкы дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүенең типовой стандартлары булган – «Россия Федерациясе субъекты (муниципаль берәмлек) бюджет үтәлеше турында еллык хисапны оештыру һәм тышкы тикшерү үткәрү», «Тикшерү һәм экспертиза-аналитика чаралары нәтиҗәләрен тормышка ашыруны тикшерү», «Экспертиза-аналитика чараларын үткәрү» дип аталган 3 методик документны әзерләүдә катнашты.

Июньдә Санкт-Петербург шәһәрендә халыкара икътисадый форум кысаларында Россия Федерациясе инициативасы буенча «Бюджет

чыгымнарының икътисадка мультипликатив эффекты. Өстенлекләр, эчке резервлар һәм тикшерү» темасына аудиторлык дискуссия панеле булып үтте. Дискуссия панеле эшендә Россия Хисап палатасы Рәисе Т.А.Голикова, Россия Федерациясенең 16 субъекты тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре, шул исәптән Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов та, шулай ук чит ил финанс тикшерүе югары органнары җитәкчеләре һәм дөнья һәм Россия фәнен чагылдыручы

экспертлар, эшлекле шәхесләр катнашты.

Июнь аенда Самара шәһәрендә Идел буе федераль округына керә торган Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары җитәкчеләренең семинар-киңәшмәсе узды. Киңәшмә өлкәнең тикшерү-хисап органына 20 ел тулуга туры китерелде һәм тикшерү-хисап органнары материалларын тормышка ашыруны тикшерү практикасына, хокук саклау органнары, прокуратура органнары белән хезмәттәшлек мәсьәләләренә багышланган иде. Семинар-киңәшмә эшендә Россия Федерациясе Хисап палатасы вәкилләре, Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре катнашты. «Дәүләт финанс тикшерүе органнарының хокук саклау органнары, прокуратура органнары белән хезмәттәшлеге: Татарстан Республикасы тәҗрибәсе» темасына доклад белән Идел буе федераль округындагы Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Советы бүлеге җитәкчесе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы башлыгы Алексей Иванович Демидов чыгыш ясады.

Июнь аенда Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасары А.Ш.Вәлиев Мәскәү шәһәрендә Дәүләт Думасының Бюджет һәм салымнар буенча комитеты оештырган «Федераль бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген үстерүнең төп юнәлешләре: чынбарлык һәм перспективалар» темасына парламент тыңлауларында катнашты. Тыңлауларда Россия Федерациясе Финанс министры А.Г.Силуанов, Россия Федерациясе Хисап палатасы Рәисе Т.А.Голикова чыгыш ясады.

Татарстан Республикасы Хисап платасы, Тышкы финанс тикшерүе региональ органнарының Европа оешмасы (ЕВРОРАИ) әгъзасы буларак, әлеге оешма уздыра торган чараларда катнаша.

Июнь аенда Санкт-Петербург шәһәрендә Тикшерү-хисап органнарының халыкара форумы узды, аның кысаларында «Регионнар һәм муниципаль дәрәҗәдә дәүләт сатып алуларына аудит» темасына ЕВРОРАИның халыкара семинары,

Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы Президиумы утырышы, шулай ук «Сатып алулар өлкәсендә аудит уздыру, анализ, куллану практикасын билгеләүче 44-ФЗ нигезләмәләрен тормышка ашыру» темасына Тикшерү-хисап органнарының Бөтенроссия конференциясе узды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасыннан андаРоссия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы тикшерү-хисап органнары советының Идел буе федераль округындагы бүлек җитәкчесе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов, Хисап палатасы аудиторы А.Р. Вәлиев катнашты. Шулай ук Хисап палатасы Рәисе октябрьдә Дрезденда (Германия) булып узган ЕВРОРАИның «Мәдәният өлкәсендә аудит – аудитор тикшерүе уздыруга һәм аның нәтиҗәләренә, аерым алганда, югары сәнгатьне үстерүгә ярдәм итү мәсьәләләренә карата, мөнәсәбәтләр буенча тәҗрибә уртаклашу» халыкара семинарында да катнашты.

Сентябрьдә Татарстан Республикасы Хисап палатасына Фудань университеты (Кытай) профессоры Ян Синьюй килде. Эшлекле очрашу барышында мөмкин булган хезмәттәшлек мәсьәләләре турында сөйләшү алып барылды.

Россия Федерациясе Хисап палатасының системалы анализ буенча Дәүләт фәнни-тикшеренү институты белән (ХП ФТИ) хезмәттәшлек кысаларында Хисап палатасы аудиторы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советының методология мәсьәләләре буенча комиссиясе Рәисе урынбасары А.Р.Вәлиев Россия Федерациясе субъектлары һәм Мәскәү, Краснодар, Сочи, Манитогорск, Екатеринбург шәһәрләрендә муниципаль берәмлекләр тикшерү-хисап органнары хезмәткәрләре өчен квалификация күтәрү курсларын үткәрүдә, Идел буе федераль округында (Чебоксар шәһәрендә), Себер федераль округында (Камчатка крае тикшерү-хисап органнары хезмәткәрләре өчен) ХП ФТИ филиалы оештырган видеоконференцияләрдә, Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарәсе Югары мәктәбендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык һәм муниципаль хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү курсларында, шулай ук Вьетнам Социалистик Республикасының Дәүләт аудиты идарәсе белгечләре өчен квалификация күтәрү курсларын үткәрүдә катнашты.

Декабрьдә Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы тикшерү-хисап органнары Президиуы һәм Советыны уртак утырышында, Россия Федерациясе Хисап палатасы тарафыннан үткәрелгән «Сатып алулар өлкәсендә контракт системасын үстерү: законнар, аудит, инструментлар» дип аталган конференциядә катнашты. Биредә Россия Федерациясе Хисап палатасы белән бергә тикшерү һәм экспертиза-аналитика чараларын әзерләү һәм үткәрүдә актив катнашканы өчен Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов Россия Хисап палатасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

2015 елда Хисап палатасы вәкилләре Казан шәһәрендә үткән халыкара чараларда: «Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге һәм энергия саклау» XV Халыкара симпозиумында, «Дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүен үстерү. Законнар, практика, институтлар» II халыкара фәнни-гамәли конференциясендә; Ульяновск шәһәрендә узган региональ форумда, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы видеоконференциясендә, Махачкала шәһәрендә Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары җитәкчеләренең Бөтенроссия киңәшмәсендә докладлар белән чыгыш ясады, шулай ук алар Чиләбе, Симферополь шәһәрләрендә узган конференцияләрдә катнаштылар.

Россия Федерациясе Хисап палатасының тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге җитәкчесе, Башкортстан Республикасы, Чувашия Республикасы тикшерү-хисап палаталары рәисләре белән эшлекле очрашулар узды.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнары, Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары Союзы белән хезмәттәшлек

Хисап елында Хисап палатасы муниципаль финанс тикшерүенең нәтиҗәлелеген үстерү, республика тикшерү-хисап органнарының хезмәттәшлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшен дәвам итте.

Муниципаль тикшерү-хисап органнарына оештыру, хокукый, методик, мәгълүмати, шул исәптән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит оештыру һәм үткәрү буенча ярдәм күрсәтелә. Барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округлары тикшерү-хисап органнарына кураторлар – аудиторлар һәм структура бүлекчәләре җитәкчеләре беркетелә.

Ай саен муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенә мониторингүткәрелә.

2015 елда республиканың муниципаль берәмлекләр тикшерү-хисап органнары тарафыннан 829 тикшерү чарасы уздырылган. Тикшерү 1 787 объектны колачлаган.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча чаралар күрелгән һәм муниципаль берәмлекләр бюджетларына 3 710,9 млн. сум күләмендәге чара кире кайтарылган.

Муниципаль тикшерү-хисап органнары җирле үзидарә органнарының муниципаль берәмлек бюджет чаралары исәбенә чыгымнарны күз алдында тоткан һәм аны формалаштыру һәм үтәлешенә йогынты ясый торган норматив хокук актлары проектларына экспертиза үткәрәләр.

2015 елда 2 132 экспертиза-аналитика чарасы үткәрелә, 1 939 эксперт бәяләмәсе әзерләнә.

2015 елның апрелендә Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советы утырышы булды. Актуаль темаларга багышланган докладлар белән Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры, Татарстан Республикасы буенча Россия Федераль салым хезмәте идарәсе җитәкчесе урынбасары чыгыш ясады.

Утырышта 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, хезмәтләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законын тормышка ашыру мәсьәләләре, аерым муниципаль тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенең төп нәтиҗәләре каралды, шулай ук «Татарстан Республикасының 2014 ел нәтиҗәләре буенча иң яхшы финанс тикшерүчесе»

исеменә бәйгегә нәтиҗә ясалды. Шундыйлар итеп Яшел Үзән, Сарман муниципаль районнары тикшерү-хисап палаталары рәисләре танылды.

Июньдә Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм республиканың 13 муниципаль тикшерү-хисап органнары вәкилләре Магнитогорск шәһәрендә Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары союзының гомуми җыелышында катнаштылар. Россия Федерациясе Хисап палатасы аудиторы, Союз Рәисе В.С.Катренко «Хәзерге заман икътисадый шартларда муниципаль тикшерү-хисап органнарының бурычлары» темасына доклад белән чыгыш ясады. Җыелыш барышында 2014 ел өчен Союз эше һәм Ревизия комиссиясе эше турында хисаплар расланды, муниципаль тикшерү-хисап органнары эшчәнлегендә хәзерге заман этабындагы өстенлекле юнәлешләр ачыкланды.

24 декабрьдә булып үткән Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советы утырышында дәүләт һәм муниципаль сатып алулар өлкәсендә аудит үткәрү, дәүләт һәм муниципаль контрактларны үтәгәндә бозулар, тикшерү-хисап органнары эшчәнлегендә административ практика, тышкы финанс тикшерүен стандартлаштыру мәсьәләләре каралды.

Муниципаль тикшерү-хисап органнары эшенең иң мөһим юнәлешләре итеп түбәндәгеләр билгеләнде:

- сатып алулар өлкәсендә аудит үткәрү;
- дәүләт чараларын нәтиҗәле куллануны тикшерүне тормышка ашыру – нәтиҗәлелек аудиты уздыру;
- дәүләт һәм муниципаль программаларга аудит уздыру;
- муниципаль контрактлар буенча туклану продуктлары белән тәэмин итүләрне һәм муниципаль учреждениеләрдә туклануны оештыруны тематик тикшерү уздыру;
- муниципаль берәмлек бюджетының керем өлешен арттыру резервларын ачыклау;
- финанс тикшерүчеләренең һөнәри дәрәҗәсен күтәрү.

Совет эшчәнлеге турында, норматив һәм методик документлар, квалификация күтәрү курслары турында мәгълүмат Хисап палатасының (http://www.sprt.tatar/) һәм Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советының (http://www.ksort.ru) рәсми сайтларында урнаштырылган.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек

2015 елда Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы кысаларында Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан алып барылган эш дәвам иттерелде.

Финанс тикшерүе органнары белән үзара хезмәттәшлек Тикшерү чараларының җыелма планына туры китереп тормышка ашырылды.

Финанс-бюджет өлкәсендә бозуларны кисәтү һәм профилактикалау максатында министрлыкларга, ведомство һәм республиканың муниципаль берәмлекләренә ел саен бозулар һәм кимчелекләрне анализлау һәм системалаштыру нәтиҗәләре буенча Бәяләмә җибәрелә.

Апрель аенда булып уз ган Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерү мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы утырышында объектлар төзү һәм реконструкцияләү, капиталь ремонтка бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү нәтиҗәләре, шулай ук уртача базар бәяләреннән дә югарырак бәягә товарлар сатып алу, һәм дәүләт (муниципаль) контрактлары шартларына туры килми торган товарлар белән тәэмин итү очраклары каралды. Бюджетка түләүләрнең үз вакытында керүен һәм тулылыгын, киң таралган файдалы казылмалар карьерларын эшләгәндә законлылык таләпләрен саклауны тикшерүне активлаштыру буенча тәкъдимнәр эшләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде.

Октябрьдә Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы утырышында дәүләт һәм муниципаль контрактларны үтәү вакытында бозулар һәм республикада эчке дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүен оештыру турында: дәүләт һәм муниципаль финанс тикшерүе органнарының бюджет вәкаләтләрен үтәвенә анализ практикасы мәсьәләләре тикшерелде.

Утырышта катнашучылар тукланулы оештыруга бүлеп бирелә торган бюджет чараларын нәтиҗәле куллануны, автоном һәм бюджет учреждениеләренең дәүләт заказларын үтәүләренең сыйфатын һәм тулылыгын тикшерү буенча эшне көчәйтүнең зарурлыгы турында фикер әйттеләр.

Дәүләт һәм муниципаль контрактларны үтәгәндәге бозулар буенча җыелма мәгълүмат идарә карарларын кабул итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Рспубликасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына җибәрелде.

Хисап палатасы, Финанслар министрлыгының Казначылык департаменты, Финанс-бюджет күзәтчелеге Федераль хезмәтенең Территориаль Идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ачыкланган бозулар буенча мәгълүматлар квартал саен гомумиләштерелде.

13 июльдә Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе һәм Хисап палатасы арасында сатып алулар өлкәсендә хокук саклау органнары һәм дәүләт финанс тикшерүе, аудит органнары арасында яңа редакциядә Килешү төзелде.

25 мартта Казанда «2014 ел хәйриячесе» республика бәйгесе җиңүчеләрен бүләкләүнең сигезенче тантанасы булып узды. Хәйриячелек хәрәкәте үсешенә 10 ел дәвамында керткән өлешен искә алып, Татарстан Республикасы Хисап палатасына «Яктылык бүләк итүче» номинациясендә бүләк тапшырылды.

Эшчәнлектә хәбәрдарлык

Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге, Хисап палатасының Коллегия, Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү Советы һәм Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнары Советы утырышлары һәрдаим массакүләм матбугат чараларында, шул исәптән федераль басмаларда да яктыртылып торды.

Хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүмат рәсми сайтта (http://www.sprt.ru), Россия Хисап палатасы һәм Россия Федерациясе Тикшерү-хисап органнары советы сайтында (http://www.portalkso.ru), шулай ук РФ Хисап палатасының Системалы анализлау дәүләт фәнни-тикшеренү институтының «АКСОР хәбәрчесе» фәнни-популяр журналында урнаштырылды. 2015 елда Хисап палатасы сайтына 29 195 тапкыр керү теркәлгән (2014 елда – 28 548, 2013 елда – 26 928, 2012 елда – 20 624).

2015 елда массакүләм мәгълүмат чараларында (интернет басмалар, журналлар, газета һәм телевидение) Хисап палатасы эшчәнлеге 198 материалда, шул исәптән: Интерфакс-Поволжье, Прайм-ТАСС, РБК, РЕГНУМ мәгълүмати агентлыкларының веб-сайтларында, E-gorlovka.com.ua веб-сайтында, «Аргументы и Факты», «Российская газета», «Коммерсантъ», газеталары, «Финконтроль» журналы кебек федераль басмаларда яктыртылган.

«Вестник АКСОР» журналында Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидовның «Татарстан Республикасы Хисап палатасы: сатып алулар системасына аудит» мәкаләсе басылып чыкты (№1, 2015).

Үткәрелгән тикшерү чараларын нәтиҗәләре буенча йомгаклау документлары, Хисап палатасы эшчәнлеге елъязмасы квартал саен Татарстан Республикасы Хисап палатасының мәгълүмати бюллетеньнәрендә басылды. Бюллетеньнар Хисап палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы әгъзаларына юлланды.